Өркеш авыл җирлеге Советы
Кукмара муниципаль районы
Татарстан Республикасы

# КАРАРЫ

От 28 января 2021 года №2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Өркеш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Өркеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы кукмара муниөипалдж районы Өркеш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итеп, (2016 елның 16 декабрендә 32 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 9 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге 1 номерлы, 2019 елның 22 августындагы 9 номерлы Өркеш авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлегенең максималь күләме – 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Глава Уркушского
сельского поселения А.Ш.Аглямова